**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592)
7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-
20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_18» _____11____ 2024 ел.** **№ __238__**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрүне билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 31 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2018 елның 22 августындагы 203-30 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә,карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сәпәй авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрүне (алга таба - гавами тыңлаулар) билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитеты билгеләргә.

3. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын, 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

5.Гавами тыңлаулар үткәрү чорын - кызыксынучы затларга үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлауларны уздыру вакыты бер айдан да артмаска тиеш.

6. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегенә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1

статьясында каралган иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр итәргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru.һәм «Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы»нда бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.З.Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы
Башлыгы карарына кушымта
«_____» ___________ 2024 №______

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем сәркатибе:* | |
| Әюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеш бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Галиева Ф.Г. | Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башлыгы (килешү буенча) |
| Латыйпова Л.И. | Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Азнакай муниципаль районы Советы авыл җирлекләре белән эшләү секторы мөдире |